Миңнуллин, Т. Уйландырды / Т. Миңнуллин // Мәдәни җомга. – 2025. – №12 (28 март). – Б. 5.

**Туфан Миңнуллин**

# Уйландырды

«Мәйдан» журналында басылган шигырьләрне караштырып утырам. Ходайның биргәненә шөкер, шигъриятебезгә тел-теш тидерерлек түгел. Оста язабыз, белеп язабыз. Тик шулай да күңел нидер эзли. Аһ дип сискәндереп куярлык шигырь очратасы килә. Уйлаганым фәрештәнең амин дигән чагына туры килдеме, мине сөендергән юллар очрады:

*һәр бәхетле мизгел өчен*
*Нидер түләргә кирәк.*
*Оҗмахка керер өчен дә,*
*Иң кимендә, һич югында,*
*Башта үләргә кирәк.*

Авторы Зөләйха Минһаҗева икән. Күңелемә кереп урнашты бит шушы гади генә шигъри фәлсәфә. Фикер болай таныш та кебек. Тик шулай җыйнак итеп, һәркем аңларлык итеп, татарча итеп әйтелгәнен укыганым юк шикелле. Әйе шул, бәхет тә түләп алына, бушка берни дә бирелми дөньяда. Мәсьәлә шунда - ни белән түлисең бит. Шунысы ачык - акча түләп кенә алып булмый торган нәрсәләр бар. Автор бәхет турында яза. әмма бәхетсезлекне дә еш кына түләп алабыз без. Уйландырды алты юллык шигырь.

2003.